**Татарстан Республикасы**
**Тукай муниципаль районы**
**Калмия авыл җирлеге составына керүче**
**Малтабар авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

# КАРАР

27 октябрь, 2022 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2021 елның 27 октябрендә узган гражданнар җыеннары нәтиҗәләре белән түбәндәге мәсьәлә буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

«2023 елда яшәү урыны буенча Калмия авыл җирлеге Малтабар авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 1000 ( бер мең сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 500 (биш йөз) сум күләмендә билгеләргә, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләне хәл итүгә юнәлдерергә Сез ризамы:

- Малтабар авылы Комсомол урамында юл ремонтлау.

ӘЙЕ ЮК».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 113 кеше кертелде, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны – 59 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча җыенда катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 59 кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 кеше тавыш бирде.

**Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар бирде:**

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Калмия авыл җирлеге Малтабар авылында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләрен гамәлдә дип таныргa.

2. «2023 елда яшәү урыны буенча Калмия авыл җирлеге Малтабар авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 1000 (бер мең) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 500 (биш йөз) сум күләмендә билгеләргә, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләне хәл итүгә юнәлдерергә Сез ризамы:

- Малтабар авылы Комсомол урамында юл ремонтлау.

3. Тукай муниципаль районы Калмия авыл җирлеге Малтабар авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырып, халыкка җиткерергә.

4. Тукай муниципаль районы Калмия авыл җирлеге Малтабар авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен Тукай муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Калмия авыл җирлеге Башлыгы Р. Ә.Гарипов